**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕРЭШ-ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XXI УТЫРЫШЫ**

**Карар № 37**

**Керэш-Шуран авылы.** **25 июль 2022 ел.**

**«"Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында Мөслим муниципаль районы авыл җирлегендә урнашкан затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрне бастырып чыгару һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесенең вазыйфасы турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керэш-Шуран авыл җирлеге Советы 2017 елнын 08 сентябрендәге 2 номерлы карарына үзгәреш кертү турында**

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Мөслим муниципаль районының Керэш-Шуран авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.«"Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында Мөслим муниципаль районы авыл җирлегендә урнашкан затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрне бастырып чыгару һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесенең вазыйфасы турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керэш-Шуран авыл җирлеге Советы 2017 елнын 08 сентябрендәге 2 номерлы карарында 3 пунктның «д» пунктчасын түбәндәге эчтәлектә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«д) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше), санлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турындагы мәгълүматлар, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлегенең һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга

3 Әлеге карар рәсми басылып чыкканан сон үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Керэш-Шуран авыл жирлеге башлыгына йөкләргә.

Керэш-Шуран авыл жирлеге башлыгы: Р.Г.Сафиуллин